Аксубай муниципаль районы Яңа Кармәт
авыл җирлеге советы
423066 **ЯңаКармәт** авылы
Муса Җәлил урамы,15а нче йорт
тел. 4-92-33 факс

Совет Новокиреметского сельского
поселения Аксубаевского муниципального
района
42306 с.Новая Киреметь
улица Мусы Джалиля, д.15а
тел. 4-92-33 факс

Муса Җәлил урамы, 15а нче йорт
Яңа Кармәт авылы , 4203066

ул. Мусы Джалиля, д 15а,
с.Новая Киреметь, 423066

Тел. (8-84344-4-92-33) ОГРН 1021605359709,
ОКПО 04311599, ИНН/КПП 1603001197/160301001
E-mail*: Nkir.Aks@tatar.ru*

# Карар

№8 2022 елның 9 нче ноябре

"Аксубай муниципаль районы Яңа Кармәт авыл җирлегенең Яңа Кармәт авыл җирлегендә халык җыены үткәрү турында"

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 елның № 131 - ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының "Яңа Кармәт авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставының 24 статьясы, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Кармәт авыл җирлеге Советының "Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Кармәт авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында" 2019 елның 5 ноябрендәге 98 номерлы карарына таянып.

Карар итте:

1. Аксубай муниципаль районы Яңа Кармәт авыл җирлеге Яңа Кармәт авылында Кызылармия, Тукай, Муса Җәлил урамнарында яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының беренче этабын 2022 елның 16 ноябрендә 10 сәгать 00 минутта билгеләргә.

2. Аксубай муниципаль районы Яңа Кармәт авыл җирлеге Яңа Кармәт авылында Жданова, Карл Маркс, Зеленая урамнарында яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының икенче этабын 2022 елның 23 ноябрендә 10 сәгать 00 минутта билгеләргә.

3.Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

3.1 ."2023 елда Аксубай муниципаль районының Яңа Кармәт авыл җирлеге Яңа Кармәт авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, балигъ булмаган һәр кешедән, I төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан, хәрби хезмәткә мобилизацияләнгән һәм көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә килешәсезме:

1) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- Яңа Кармәт урамнарына вак таш түшәлгән юллар төзелеше (сатып алу, ташу, җәю, вак таш, туфракны тигезләү, ком һәм грунттан нигез салу, килешү буенча эшләр өчен түләү)

- кышкы чорда Яңа Кирмәт авылы эчендәге юлларны карап тоту, урамнарны кардан чистарту килешүе буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү..

2) Ритуаль хезмәтләрне оештыру һәм күмү урыннарын тоту

- Яңа Киремәт авылы зиратында агач һәм үсентеләр кисү килешүе буенча хезмәтләр өчен түләү

"ӘЙЕ" " ЮК" "ТЫЕЛЫП КАЛДЫ"

3. Җыеннар үткәрү урыны-ТР, Аксубай районы, Яңа Кармәт авылы, Муса Җәлил урамы, 15а йорт адресы буенча урнашкан Яңа Кармәт авыл мәдәният йорты .

4. Җыенны оештыру һәм үткәрү өчен җаваплылыкны Яңа Кармәт авыл җирлеге башкарма комитетына йөкләргә.

5. Әлеге карарны Яңа Кармәт авыл җирлегенең рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча бастырырга: http://aksubaevo.tatar.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru) Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә

6. Әлеге карар кабул ителгән көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районының
Яңа Кармәт авыл җирлеге башлыгы И. Р. Шакиров